**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 15 июнь | № 405

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 октябрь, 507 нче; 2006 ел, 18 апрель, 192 нче; 2006 ел, 21 апрель, 199 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 621 нче; 2008 ел, 28 март, 196 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче; 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1042 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 март, 197 нче; 2011 ел, 13 сентябрь, 762 нче; 2012 ел, 16 март, 221 нче; 2012 ел, 24 март, 237 нче; 2012 ел, 6 август, 668 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1153 нче; 2013 ел, 31 гыйнвар, 54 нче; 2013 ел, 14 март, 161 нче; 2013 ел, 14 май, 323 нче; 2014 ел, 12 апрель, 238 нче; 2014 ел, 8 июль, 471 нче; 2014 ел, 8 август, 575 нче; 2015 ел, 10 август, 578 нче; 2015 ел, 24 декабрь, 969 нчы; 2016 ел, 22 гыйнвар, 32 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 пунктның 3.3.3 ярдәмче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында яшәүче картасы» проектын тормышка ашыруда катнашучы кредит оешмаларына Татарстан Республикасында яшәүчеләр карталары реестрының веб-сервисыннан һәм Татарстан Республикасында яшәүче картасын чыгару (кабат чыгару) өчен кирәкле мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеген бирү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков